Аксубай районы Иске Кыязлы төп гомуми белем бирү мәктәбе педагогик киңәшмәсендә каралды һәм кабул ителде.
“29” август 2018 ел.

Расланды
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы төп гомуми белем бирү мәктәбе директоры ________ Мугинов И.С.
Беркетмэ №52 “31” август 2018 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы “Иске Кыязлы төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең мәктәпкә әзерлек төркеме өчен 2018-2019 уку елына эш программасы (МББ ФДББС буенча).

“Туганнан алып мәктәпкәчә” Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы (Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.. Васильева редакциясендә) “Балалар бакчасының төп белем бирү программасы нигезендә төзелде”.

Тәрбияче: ________ Р.Ә. Җәләлетдинова.
________ З.Г.Шәмсетдинова

**Эчтәлек**

**1. Максатчан бүлек**
1.1.Аңлатма язуы........................................................................................................................................4
1.1.1. Программаның максаты һәм бурычлары.........................................................................................4
1.1.2.Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары..................................................................5
1.2. 6-7 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре.......................................................................6
1.3. Төркем эшчәнлегенең төп юнәлеше.....................................................................................................8
1.3.1. Мәктәпкә әзерлек төркеменә йөрүче балалар исемлеге.....................................................................9
1.4.Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре...............................................................10
**2.Эчтәлек бүлеге**
2.1.Белем бирү өлкәләре..........................................................................................................................11
2.1.1.“Социаль-коммуникатив үсеш” белем бирү өлкәсе.........................................................................11
2.1.1.1. Мәктәпкә әзерлек төркемендәге балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча перспектив план......................................13
2.1.2.Перспектив планнар ........................................................................................................17
2.1.3 “Физик үсеш” белем бирү өлкәсе......................................................................................................41
2.1.4.“Сәнгати-эстетик үсеш” белем бирү өлкәсе......................................................................................56
2.1.5. Сөйләм үсеше (сөйләм үстерү)...........................................................................................................69
2.1.6. Комплекслы- тематик план...............................................................................................................81
2.4.Гаилә белән үзара бәйләнеш..............................................................................................................88
2.4.1. Ата-аналар белән эшнең перспектив планы .......................................................................................89
**3. Оештыру бүлеге**
3.1. Мәктәпкә әзерлек төркеменең көндәлек режимы ..............................................................................92
3.2.Мәктәпкә әзерлек төркемендә төп белем бирү эшчәнлеге расписаниесе............................................94
3.3.Төркемнең социаль паспорты.............................................................................................................95
3.4..Сәламәтлек-профилактика планы......................................................................................................96

3.5..Күңел ачу чаралары исемлеге........................................................................................................................................97
3.6..Программа һәм методика белән тәэмин итү........................................................................................................................97
3.7..Үстерешле-предметлы  тирәлек............................................................................................................................................99
3.8 .Кулланылган әдәбият..........................................................................................................................................................100

# I. МАКСАТЧАН БҮЛЕК
## 1.1.Аңлатма язуы

Төркемнең эшчәнлеге төп белем бирү программасының үтәлешенә юнәлгән һәм түбәндәге документларга нигезләнә "Закон об образовании в Российской Федерации" (Принят 29 декабря 2012года № 273-ФЗ);

-"Санитарно-эпидемиологическими требованиями к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных организациях" (Постановление от 15 мая 2013 года № 26 "Об утверждении СанПиН 2.4.1.3049-13");

- Приказ Минобразования Российской Федерации "Об утверждении Федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования" от 17.10.2013 № 1155;

- Закон РТ № 44 от 28.07.2004г. "О государственных языках РТ и других языках в РТ".

- Әлеге программа "Туганнан алып мәктәпкә кадәр". Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү Программасы (Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясе астында) Москва «Мозаика-Синтез», 2010, "Балалар бакчасының төп белем бирү программасы", Шаехова Р.К. : Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы"на нигезләнеп төзелде.

### 1.1.1. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның төп максаты — баланың мәктәпкәчә балачагын тулыканлы уздыру өчен уңай шартлар тудыру; бурычлары - шәхеснең база культурасы нигезләрен формалаштыру, яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, психик һәм физик сыйфатларны һәрьяклап үстерү, хәзерге җәмгыятьтәге тормышка әзерләү, уку эшчәнлегенә алшартлар формалаштыру, мәктәпкәчә яшьтәге баланың тормыш иминлеген тәэмин итү.

Программада баланың шәхесен үстерүгә, балаларның сәламәтлеген ныгытуга һәм саклауга, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларда патриотизм, актив тормыш позициясе, тормышта килеп туган төрле хәлләрдән чыгу юлларын таба белү, традицион кыйммәтләргә карата хөрмәт кебек сыйфатлар тәрбияләүгә аеруча игътибар бирелә. Әлеге максатлар балалар эшчәнлегенең төрле төрләре: уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив (рәсем ясау, конструктив һ.б.), музыка белән шөгыльләнү, уку процессларында гамәлгә ашырыла.

Программаның максатларына ирешүдә түбәндәгеләр беренче дәрәҗә мөһим:

• һәрбер баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яктан үсеше турында кайгырту;

• төркемнәрдә барлык тәрбияләнүчеләргә карата аларны аралашучан, яхшы күңелле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерергә ярдәм итәрлек кешелекле һәм яхшы мөнәсәбәт булдыру;

• балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен максималь файдалану, тәрбия-белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында аларны интеграцияләү;

• тәрбия-белем бирү процессын иҗади оештыру;

•белем бирү материалын куллануның вариативлыгы, һәрбер баланың кызыксынулары һәм сәләтләренә туры китереп иҗат эшен үстерергә мөмкинлек бирү;

• балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау;

• мәктәпкәчә белем бирү төркемендә һәм гаилә шартларында балалар тәрбияләүгә бердәм якын килү;

•балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү эчтәлегендә акыл һәм физик яктан көч килүләрне булдырмаучы, предметлы укыту басымы ясамауны тәэмин итүче дәвамчанлыкны үтәү.

### 1.1.2.Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары

Программада белем бирүнең бала шәхесен формалаштыруны тәэмин итүче һәм педагогны аның индивидуаль үзенчәлекләренә юнәлтүче үстерү функциясе беренче планга чыга. Программа балага карата гуманлылык һәм шәхес итеп карау мөнәсәбәтләрендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләрен, шулай ук сәләтләрен һәм интегратив сыйфатларын формалаштыруга юнәлтелгән. Программада баланы туганнан алып мәктәпкәчә тәрбияләүнең һәм аңа белем бирүнең барлык төп эчтәлек юнәлешләре комплекслы күрсәтелә.

Программаны формалаштыру принциплары

• баланың үсешенә ирешүне максат итеп куйган үсешкә китерүче белем бирү принцибына туры килә;

• фәнни нигезләнгәнлек һәм гамәлдә кулланучанлык принципларын исәпкә ала (Программаның эчтәлеге яшь чорлары психологиясе һәм мәк-тәпкәчә педагогиканың төп нигезләмәләренә туры килә һәм, тәҗрибәләр күрсәткәнчә, массакүләм мәктәпкәчә белем бирү практикасында уңышлы гамәлгә ашырыла ала);

• тулылык, зарурлык һәм җитешлелек критерийларына туры килә (җитәрлек күләмдә «минимум» материал кулланганда, куйган максатлар һәм бурычларны хәл итәргә мөмкинлек биреп);

• мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү процессының тәрбияви, үсеш һәм укыту максатлары һәм бурычлары бергәлеген тәэмин итә, аларны гамәлгә ашыру барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешенең нигезен тәшкил итүче сыйфатлар формалаша;

• балаларның яшь мөмкинлекләренә һәм үзенчәлекләренә, белем бирү өлкәләренең үзенчәлегенә һәм мөмкинлекләренә туры китереп, белем бирү өлкәләренең интеграциясе принцибын исәпкә алып төзелә;

• белем бирү процессын коруның комплекслы-тематик принцибына нигезләнә;

• программалы белем бирү бурычларын өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә хәл итүне турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, мәктәпкәчә белем бирүнең үзенчәлегенә туры китереп, режим моментларын уздырган вакытта да күздә тота;

• белем бирү процессын балалар белән эшләүнең яшь үзенчәлекләренә туры килгән формаларын куллану аша оештыруны күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүнең төп формасы һәм алар эшчәнлегенең әйдәп баручы төре булып уен исәпләнә;

• төбәк үзенчәлекләренә бәйле рәвештә белем бирү процессын төрләләндерүгә юл куя;

• мәктәпкәчә яшьтәге барлык төркемнәр арасында һәм балалар бакчасы белән мәктәп арасында дәвамчанлыкны саклауны исәпкә алып төзелә

## 1.2. 6-7 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре

Сюжетлы-рольле уеннарда җиденче яшькә чыккан балалар өлкәннәрнең әһәмиятле тормыш вакыйгаларын чагылдыручы катлаулы мөнәсәбәтләрен үзләштерә башлыйлар. Мәсәлән, туй, бала туу, авыру, эшкә урнашу һ.б. Уен элементлары катлаулана, олы кешегә һәрвакытта да ачылып бетми торган мәгънә ала бара. Уен пространствосы катлаулана. Анда берничә үзәк булып, һәркайсының үз сюжет сызыгы була. Шул ук вакытта балалар бергә уйнаган иптәшләренең үз-үзләрен тотышын барлык уен пространствосы буйлап күздән ычкындырмаска һәм кирәк вакытта уенның урынына бәйле рәвештә үзгәртергә сәләтлеләр. Мәсәлән, бала кибетчегә сатып алучы буларак кына түгел, ә сатып алучы әни яки сатып алучы шофер буларак мөрәҗәгать итә. Рольне башкару рәвеше рольнең үзе белән генә түгел, ә бу рольнең уен пространствосьгадагы урыны белән дә билгеләнә. Мәсәлән, автобус йөртүче ролендә бала пассажирлар өстеннән командалык итә һәм шул ук вакытта ЮХИДИ инспекторына буйсына. Әгәр дә уен логикасы яңа роль барлыкка килүен таләп итсә, бала, уен барышында үз ролен саклаган хәлдә, яна рольне үз өстенә алырга мөмкин. Балалар теге яки бу уенчының ролен ничек башкаруына аңлатма бирә алалар. Балаларның сынлы сәнгать эшчәнлегендә әйләнә-тирә тормыштан һәм әдәби әсәрләрдән алып сурәтләгән образлары катлаулана бара.

Рәсемнәр детальләшкәнрәк характер ала, аларның буяулар гаммасы байый. Кызлар һәм малайлар рәсемнәре арасында аермалык күзгә ташлана. Малайлар бик теләп техника, галәм, сугыш хәрәкәтләре һ.б. ясыйлар. Кызлар, гадәттә, хатын-кыз образларын сурәтлиләр: принцессалар, балериналар, модельләр һ.б. Еш кына көнкүреш сюжетлары да очрый: әнисе һәм кызы, бүлмә күренеше һ.б. Педагогик яктан дөрес якын килгәндә, балаларда сынлы сәнгать өлкәсендә иҗади сәләт формалаштырырга мөмкин. Кеше сурәте тагын да

детальләшкән һәм пропорциональ була бара. Күзләр, авыз, борын, кашлар, ияк ясала, кул бармаклары да барлыкка килә. Киемнәре төрле детальләр белән бизәлергә мөмкин.

Мәктәпкә хәзерлек төркеме балалары төзү материалларыннан конструкцияләрне шактый югары дәрәҗәдә үзләштерәләр. Алар сурәтләрне, шулай ук корылмаларны анализлауның гомуми алымнарын иркен үзләштерәләр, аерым детальләрнең төп конструктив үзенчәлекләрен анализлап кына калмыйча, күләмле таныш предметлар белән охшатып, аларның формасын да билгели алалар. Ирекле корылмалар симметрияле һәм пропорциональ була башлый, аларны төзү күреп ориентлашу нигезендә тормышка ашырыла. Балалар корылманын нинди эзлеклелектә төзеләчәген һәм аның өчен нинди материал кирәк буласын бик яхшы күзаллыйлар һәм үзләре уйлап чыгарып яки уенның шарты буенча шактый катлаулы корылмаларны төзи алалар. Бу яшьтә балалар инде кәгазь битен бөкләүнең катлаулы формаларын үзләштерә һәм үз формаларын уйлап чыгаралар, ләкин моның өчен аларны махсус өйрәтергә кирәк. Эшчәнлекнең бу төре балаларның тирә-юньне күзаллауларын тирәнәйтү өчен бик зур әһәмияткә ия. Табигый материалдан конструкцияләү катлаулана. Балалар алдан уйлап, төрле мөнәсәбәтләрне чагылдырган, кеше һәм хайван фигуралары кергән бербөтен композицияләр төзиләр.

Кабул итү сәләте үсә, ләкин балалар һәрвакытта да әйбернең берничә төрле билгесен берьюлы исәпкә алын бетерә алмыйлар. Образлы фикерләү сәләте үсә, ләкин үлчәм мөнәсәбәтләрен кабаттан торгызу бала өчен авырлык тудыра. Моны тикшереп карыйк. Балаларга төрле урында 9 нокта ясалган үрнәкне яңадан ясарга кушабыз. Кагыйдә буларак, балалар рәсемендәге нокталар, рәсемнәрне бер-берсе өстенә салганда, үрнәктәге нокталар белән туры килми.

Гомумиләштерү һәм фикер йөртү күнекмәләре үсү дәвам итә, ләкин алар күп очракта ситуациянең күрсәтмә билгеләре белән чикләнәләр. Уйлап чыгару сәләте дә үсә, ләкин бу зурлар төркеме белән чагыштырганда, шактый түбән. Моны төрле йогынтылар белән, бигрәк тә балаларның образларын бертөрлегә әйләндерүче массакүләм мәгълүмат чаралары йогынтысы белән аңлатырга була. Балаларның игътибарлылыгы арта бара. Алар кайбер эшчәнлек вакытында 30 ар минут игътибарларын туплап утыра алалар. Балаларның сөйләме, аның аваз ягы, грамматик төзелеше, лексикасы үсә. Бәйләнешле сөйләмнәре дә шомара. Сөйләмнең бу яшьтә формалаша торган гомумиләштерү характеры да чагыла. Балалар актив рәвештә гомумиләштерүче исемнәр, синонимнар, антонимнар, сыйфатлар һ.б. куллана башлыйлар. Дөрес оештырылган белем бирү процессы нәтиҗәсендә балаларда диалогик сөйләм һәм монологик сөйләмнең кайбер төрләре үсә. Мәктәпкә хәзерлек төркемендә мәктәпкәчә яшь чоры тәмамлана. Балалар кешелек культурасының аерылгысыз өлеше булган әйберләр дөньясы белән танышалар; кешеләр белән позитив аралашу формаларын үзләштерәләр; укучы позициясе формалаша. Мәктәпкәчә яшьнең ахырына бала шактый югары дәрәҗәдәге танып белүчәнлеккә һәм шәхес буларак үсешкә ия була. Бу сыйфатлар аның киләчәктә мәктәптә уңышлы укуын тәэмин итә.[1] (246 бит)

### 1.3. Төркем эшчәнлегенең төп юнәлеше

Мәктәпкә әзерлек төркемендә барлыгы 1 бала.   татар милләтеннән.

Бүген җәмгыятьтә катлаулы социаль-экономик процесслар бара, белем бирүнең кыйммәтләре һәм максаты тамырдан үзгәрә. Балаларга белем бирүнең бөтен өлкәләрендә дә актив, иҗади, үзен үзгәртергә әзер торучы шәхес тәрбияләү танылa. Балаларның шәхси һәм социаль мөнәсәбәт позициясен күздә тотып, аларны мәктәпкә әзерләүдән күчү, мәктәпкәчә белем бирү нәтиҗәләренең күзаллавын үзгәртергә булыша. Нәтиҗәлелек: мәктәпкәчә яшьтәге балаларда кызыксынучанлык, активлык, мөстәкыйльлек сыйфатларын формалаштыра; ялгышларны уңышсызлыкларны җиңеп чыгарга әзерлек, яңа белем алырга, стандарт булмаган ситуацияләрдән чыгу юлын эзләргә омтылыш тудыра; үзе сайлаган эшкә җаваплылык, командада эшли белү, үзенә, башкаларга, җәмгыятькә, әйләнә-тирәгә ихтирамлы караш, кайгыртучнлык тәрбияли. Болар барысы да баланы мәктәпкә әзерләп кенә калмый, ә хәзерге җәмгыятьтә уңышлы мөстәкыйль эшләү өчен нигез булып тора. Билгеле, мондый нәтиҗәләргә ирешү өлкәннәрнең фикер йөртүендәге үзгәртеп корулар белән бәйле, педагоглар һәм ата-аналар үзгәртеп корудa үзләре башлап йөрергә тиеш. Шунлыктан, Программа педагог-бала-ата-ана мөнәсәбәтенә ориетлаштырылган.

**Вариатив өлеш**

Программаның вариатив өлеше З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева, Р.С.Зөфәрова һ.б.төзегән «Туган телдә сөйләшәбез» укыту-методик комплектына нигезләнеп алып барыла. Әлеге методик ярдәмлек балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыру максатын күздә тотып төзелгән. Ул түбәндәге бурычларны билгели:

- балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
- тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
- бәйләнешле сөйләм үстерү;
- тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Икенчесе- Шаехова Р.К. "Авазларны уйнатып" методик кулланмасы максатчан рәвештә мәктәпкә әзерлек төркеме балаларын тәкъдим ителгән һәр сүзгә аваз анализы ясарга: сузык авазларны, калын һәм нечкә әйтелешле тартык авазларны аера белергә, теге яки бу сүзне барлыкка китергән авазлар рәтендә ориентлашырга, бирелгән модельләргә туры китереп сүзләр сайларга өйрәтә.

Сүзләргә аваз анализы - Программа таләп иткән уку эшчәнлегенең берничә адымын үз эченә алган бик катлаулы бурыч. Әлеге бурычны эффектив хәл итүдә "Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып" дип аталган эш дәфтәрләрен кулланабыз.

Рус телен өйрәтүне С.Гаффарованың "Изучаем русский язык" программасына нигезләнеп алып барабыз. Рус теленә өйрәтүнең төп бурычы: телдән аралашу, сөйләшүнең башлангыч белем һәм күнекмәләрен булдыру. Өйрәтү дәверендә балалар русча сөйләмне аңлый, кабул итә, өйрәнгән сүзләрне, грамматик формаларны, җөмләләрне, катлаулы булмаган бәйләнешле сөйләм үрнәкләрен куллана белергә өйрәнәләр.

**1.3.1. Мәктәпкә әзерлек төркеменә йөрүче балалар исемлеге**

| № п/п | Баланың Ф.И.О | Туган көне һәм елы |
|---|---|---|
| **Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)** | | |
| 1. | Замалеев Нэзир Марселевич | 14.06.2012 |

**1.4.Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**

Максат ориентирлары:

• Бала төп мәдәни чараларны, эшчәнлек ысулларын үзләштерә, эшчәнлекнең төрле төрләрендә — уенда, аралашуда, танып белү-тикшеренү эшчәнлегендә, конструкцияләүдә һ.б да инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтә; үзенә шөгыль төрен, уртак эшчәнлек буенча катнашучыларны сайлап алырга сәләтле.

• Бала дөньяга, хезмәтнең төрле төрләренә, башка кешеләргә һәм үз-үзенә карата уңай мөнәсәбәткә ия, аңа үзенең урынын белү хас; яшьтәшләре һәм зурлар белән актив аралаша, уртак уеннарда катнаша.

• Килешүләргә, башкаларның ихтыяҗлары һәм хисләре белән исәпләшергә, аларның уңышсызлыкларын бүлешергә һәм уңышларына сөенергә сәләтле, үз хисләрен, шул исәптән үзенә ышаныч хисен дөрес белдерә, каршылыкларны чишәргә тырыша. Төрле мәсьәләләр буенча үз позициясен аңлатырга һәм якларга сәләтле.

• Уртак эшчәнлектә хезмәттәшлеккә һәм лидерлык, һәм башкару функцияләрен дә үтәргә сәләтле.

• Барлык кешеләрнең дә, социаль чыгышлары, нинди этник төркемгә керүләренә, дини һәм башка инануларына, физик һәм психик үзен-

чәлекләренә карамастан, тигез икәнен аңлый.

• Башка кешеләргә карата эмпатиягә ия, мохтаҗларга ярдәмгә килергә әзер тора.

• Башкаларны тыңлый белә һәм башкаларның да үзен аңлауларына омтыла.

• Баланың хыялга бирелүе үсешкә ирешкән, ул эшчәнлекнең төрле төрләрендә, һәм барыннан да элек уенда, гамәлгә ашырыла; уенның төрле формаларын һәм төрләрен уйный белә, шартлы һәм чынбарлыктагы хәлләрне аера ала; төрле кагыйдәләрне һәм социаль нормаларны үтәргә сәләтле. Килеп туган төрле хәлләрне тотып ала һәм аларны дөрес бәяли белә.

• Бала сөйләм теленә шактый оста, үзенең уйларын һәм теләкләрен белдерә, сөйләмне үзенең уйларын, хисләрен һәм теләкләрен аңлату өчен, аралашу вакытында сөйләм тезмәләре төзү, сүзләрдә авазларны аерып карау

өчен куллана ала, балада грамоталылыкның алшартлары формалаша.

• Балада эре һәм вак моторика үскән; ул хәрәкәтчән, түзем, төп хәрәкәтләрне ясый белә, үз хәрәкәтләрен тикшерә һәм алар белән идарә итә ала.

• Бала ихтыяр көчен җыярга сәләтле, эшчәнлекнең төрле төрләре вакытында социаль тәртип нормаларын һәм кагыйдәләрен үти ала, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләрдә иминлекне саклау тәртибе кагыйдәләрен һәм шәхси гигиена күнекмәләрен үти ала.

• Башланган эш өчен җаваплылык сизә.

• Кызыксынучанлык күрсәтә, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә сораулар бирә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре белән кызыксына, табигать күре-

нешләренә һәм кешеләр кылган гамәлләргә карата мөстәкыйль рәвештә аңлатмалар табарга тырыша; күзәтергә, экспериментлар ясарга һәвәс. Үзе турында, табигый һәм үзе яшәгән социаль дөнья турында башлангыч белемнәргә ия, балалар әдәбияты әсәрләре белән таныш, тере табигать, табигать белеме, математика, тарих һ.б. өлкәләр буенча элементар күзаллаулары бар; эшчәнлекнең төрле төрләре буенча, үзенең белем һәм күнекмәләренә таянып, карарлар кабул итүгә сәләтле.

• Яңалыкны кабул итәргә әзер, ягъни белем алуга, алга таба мәктәптә, институтта укуга карата уңай мотивациягә омтылыш күрсәтә.

• Тормышка (аның төрле формаларында) хөрмәт белән карый һәм әйләнә-тирә мохит турында кайгырта.

• Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгына, халык сәнгате һәм профессиональ сәнгать әсәрләренә (музыкага, биюгә, театраль эшчәнлеккә, рәссамлык эшчәнлегенә һ.б.ш.) эмоциональ бәя бирә.

• Патриотик хисләр кичерә, үз иле, аның казанышлары белән горурлана,аның географик төрлелеге, күпмилләтлелеге, иң мөһим тарихи вакыйгалары хакында күзаллаулары бар.

• Үзе, гаилә, традицион гендер юнәлешләрен дә эченә алган традицион гаилә кыйммәтләре хакында беренчел күзаллауларга ия, үз җенесенә һәм капма-каршы җенескә карата ихтирамлы.

• Гомуми кабул ителгән элементар нормаларны үти, «нәрсә яхшы, нәрсә начар» булуы турында беренчел күзаллауларга ия, яхшы гамәлләр кылырга омтыла; өлкәннәрне хөрмәт итә һәм кечкенәләр турында кайгырта.

• Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллауларга ия. Сәламәт яшәү рәвешен кыйммәт буларак кабул итә.

**Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләр буенча мониторинг**

Программа үзләштерүнең арадаш нәтиҗәләре буенча монитринг елына ике тапкыр үткәрелә. Программа таләпләренең балалар тарафыннан уңышлы үзләштерелүе чын эшчәнлек процессында бәяләнә, чөнки үсеш тасвирламасы булып теге яки бу мәгълүматның формаль үзләштерелүе генә түгел, ә аны практик эшчәнлектә куллана белү тора. Балаларның планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүе буенча мониторинг системасы арадаш нәтиҗәләрне һәм программаны үзләштерүнең йомгаклау нәтиҗәләрен бәяләүне күздә тота.

## 2.ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ

### 2.1. Белем бирү өлкәләре

#### 2.1.1.“Социаль-коммуникатив үсеш” белем бирү өлкәсе.

Социаль-коммуникатив үсеш, әхлакый һәм рухи кыйммәтләрне кертеп, җәмгыятьтә кабул ителгән нормаларны һәм кыйммәтләрне үзләштерүгә; баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуын һәм үзара бәйләнешен үстерүгә; мөстәкыйльлеген, максатчанлыгын һәм үз гамәлләрен үзе җайга салуын булдыруга; социаль һәм эмоциональ интеллектны, киң күңеллелекне, хәлгә керә белүне үстерүгә, яшьтәшләре белән уртак эшчәнлеккә әзерлек формалаштыруга, Оешмадагы балалар һәм өлкәннәр бергәлеге һәм үз гаиләләренеке булу хисен һәм аларга ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүгә; хезмәтнең һәм иҗатның төрле төрләренә уңай караш формалаштыруга; көнкүрештә, социумда, табигатьтә үз-үзеңне имин тоту нигезләрен булдыруга юнәлтелгән[2] (48,49 бит).

#### 2.1.2.“Танып белү үсеше” белем бирү өлкәсе

Танып белү үсеше баланың мәнфәгатьләре, кызыксынучанлыгы һәм танып белү омтылышы үсешен; танып белү гамәлләре, аңы формалашуын; хыялы һәм иҗади активлыгы үсешен; үзе, башка кешеләр, әйләнә-тирәдәге объектлар, әйләнә-тирәдәге объектларның үзлекләре һәм үзара бәйләнешләре (форма, төс, үлчәм, материал, яңгыраш, ритм, темп, микъдар, сан, өлеш һәм бөтенлек, тирәлек һәм вакыт, хәрәкәт һәм тыныч халәт, сәбәпләр һәм нәтиҗәләр һ.б.), туган җир һәм Туган ил турындагы беренчел күзаллаулары, халкыбызның социомәдәни кыйммәтләре, Ватаныбызның традицияләре, кешеләрнең уртак һәм гомуми йорты буларак Җир планетасы, аның табигатенең үзенчәлекләре, дөньядагы илләрнең һәм халыкларның күптөрлелеге турындагы күзаллаулары формалашуын күз алдында тота[5] (65 бит).

#### 2.1.3. “Сөйләм үсеше” белем бирү өлкәсе

Сөйләм үсеше аралашу һәм мәдәният чарасы буларак сөйләмгә ия булуны; актив сүзлекне баетуны; бәйләнешле, грамматик яктан дөрес диалогик һәм монологик сөйләмне; сөйләм иҗаты үсешен; сөйләмнең аваз һәм интонация культурасы, фонематик ишетү сәләте

үсешен; китап культурасы, балалар әдәбияты белән танышуны, балалар әдәбиятының төрле жанрлары текстларын ишетеп аңлауны; укырга-язарга өйрәтүнең алшарты буларак авазлы аналитик-синтетик активлык формалашуны үз эченә ала[5].(93 бит)

### 2.1.4.“Сәнгати-эстетик үсеш” белем бирү өлкәсе

Сәнгати-эстетик үсеш сәнгать (сүз-тел сәнгате, музыкаль, сынлы сәнгать) әсәрләрен, табигать дөньясын кыйммәт-мәгънә ягыннан кабул итү һәм аңлау алшартлары үсешен; әйләнә-тирә дөньяга карата эстетик мөнәсәбәт барлыкка килүне; сәнгать төрләре турында элементар күзаллаулар формалашуны; музыканы, матур әдәбиятны, фольклорны аңга кабул итүне; әдәбиәсәрләр персонажларының кичерешләрен уртаклашуны стимуллаштыруны; балаларның мөстәкыйль иҗади (сурәтләү, конструкцияләү-модельләү, музыкаль һ.б.) эшчәнлеген гамәлгә ашыруны күздә тота[5].(103 бит)

### 2.1.5 “Физик үсеш” белем бирү өлкәсе

Физик үсеш балалар эшчәнлегенең түбәндәге төрләрендә тәҗрибә булдыруны үз эченә ала: хәрәкәтләнү, шул исәптән координация һәм сыгылмалылык кебек физик сыйфатларны үстерүгә юнәлтелгән, организмның терәк-хәрәкәт системасын дөрес формалаштыруга, тигезлек саклауга, хәрәкә һәм организмга зыян салмаслык итеп башкарылган атлап йөрү, йөгерү, җиңелчә сикерүләр, ике якка да борылулар кебек күнегүләрне эшләү белән бәйле хәрәкәт эшчәнлеге; спортның кайбер төрләре турында башлангыч күзаллаулар формалашуда, һ.б.[5](130 бит).тне координацияләүгә, кулларның эре һәм вак моторикасына булышлык итүче, шулай ук төп хәрәкәтләре дөрес һәм организмга зыян салмаслык итеп башкарылган атлап йөрү, йөгерү, җиңелчә сикерүләр, ике якка да борылулар кебек күнегүләрне эшләү белән бәйле хәрәкәт эшчәнлеге; спортның кайбер төрләре турында башлангыч күзаллаулар формалашуда,х.б.

**2.1.1.1. Мәктәпкә әзерлек торкемендәге балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәту буенча перспектив план**

| № | Темасы | Максаты | ае |
|---|---|---|---|
| 1. | Җәяүлеләр һәм пассажир-лар өчен кагыйдәләр | Балаларда юлда, җәмагать транспортында үз-үзеңне тоту турында белемнәрен булдыру. | сентябрь |
| 2. | Син- пассажир | Балаларга пассажирның кем булуын төшендерү. | |
| 3. | Ш.Галиевның "Автобуста" шигырен уку. Җәмагать транспортында әдәплелек тәрбияләү | Җәмагать транспортында әдәплелек тәрбияләүне дәвам итү. Үз-үзеңнең һәм иптәшеңнең җәмагать транспортында тотышына нәтиҗә чыгарырга өйрәтү. | |
| 4. | Юл хәрәкәте. Хәрәкәтле уен "Автомобиль һәм чыпчыклар" | Юл һәм андагы хәрәкәт турында балаларда башлангыч мәгълүмат бирү, юл кыркынычсызлы-гы кагыйдәләрен яшь үзенчәлекләренә туры китереп аңлату, транспорт төрлелеге турында әйтеп узу. | |
| 5. | Минем авылым. | Балаларны ориентлашырга өйрәтү,балаларның ике яклы хәрәкәтле юлны аркылы чыгу ту-рында белемнәрен киңәйтү, киңлектә динамик күзаллауны , күз үлчәмен, шартлы билгеләр (юл билгеләре) күргәндә фикерләүнең символик функцияләрен үстерү. Шәхси һәм җәмәгать транспортларында балаларның үзләрен тоту культурасы күнекмәләрен формалаштыру. | октябрь |
| 6. | Шәһәр урамы. | Балаларның урамда үзләрен тоту кагыйдәләрен, юл хәрәкәте кагыйдәләре, транспорт төрләре турында белемнәрен ныгыту. | |
| 7. | Авыл урамында транспорт хәрәкәтен күзәтү. | Балаларны юл йөрү кагыйдәләре б/н таныштыруны дәвам итү, урамда дөрес йөрергә өйрәнү, җәяүлеләр өчен булган кагыйдәләрне истә калдыру, юл билгеләре турында белемнәрен ныгыту. Кибет, мәктәп, балалар бакчасы һ.б. урнашкан урыннарны белергә, аларга куркынычсыз бару юлын өйрәтү. | |
| 8. | Транспорт төрләре (су транспорты, һава транс-порты); транспортлар ту-рында табышмаклар әйтешү | Балаларны юл йөрү кагыйдәләре б/н таныштыруны дәвам итү, урамда дөрес йөрергә өйрәнү, җәяүлеләр өчен булган кагыйдәләрне истә калдыру, транспорт төрләре турындагы белемнә-рен ныгыту . | |
| 9. | Дидактик уен "Сүзләр рәтен | Фикерләү тизлеген тәрбияләү, предметларны классификацияләү күнекмәсен | ноябрь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | дәвам ит". | үстерү. | |
| 10. | Юл. Бер яклы һәм ике яклы хәрәкәт | Балаларның җәяүлеләр өчен урамда йөрү кагыйдәләре, юлның транспорт йөри торган урыннарда юлны аркылы чыгу кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту; бер яклы һәм ике яклы хәрәкәт, бүлү сызыклары төшенчәләре белән таныштыру. Урамда үз-үзеңне тоту культурасы күнекмәләрен тәрбияләү. | |
| 11. | Ш.Галиевнең "Светофор-ның өч күзе" шигырен яттан өйрәнү. | Балаларның алган белемнәрен ныгыту. | |
| 12. | Регулировщик - кем ул? | Регулировщикның кулына каралы-аклы таяк тоткан, күкрәгендә билгесе булган полиция хез-мәткәре булуын аңлату. Аның һәр хәрәкәтенең светофорның бер сигналына тәңгәл килүен өйрәтү. | |
| 13. | "Җәяүле фәннәр мәктәбе" | Балаларны юл чатларында җәяүлеләрнең хәрәкәтен регламентлаучы юл билгеләре белән таныштыру | декабрь |
| 14. | Шәһәр урамы. | Балаларны шәһәр урамы һәм аның төп өлешләре белән таныштыру. Сигналны тыңлый белү күнекмәләре, игътибарлылык тәрбияләү | |
| 15. | Җәяүлеләр һәм пассажир-лар өчен кагыйдәләр. Дид./ у. "Билгеләрне урнаштыр" | Җәяәүлеләр өчен булган кагыйдәләр б\н таныштыруны дәвам итү. Балаларның юл билгеләре белән кызыксынуларын арттыру. Фигураларны танып белү, фикерләү сәләтен үстерү. | |
| 16. | Экскурсия "Шәһәр урамнарында транспорт хәрәкәтен күзәтү". | Балаларны юл йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү, урамда дөрес йөрергә өйрәтү; җәяүлеләр өчен булган кагыйдәләрне өйрәнү. | |
| 17 | Транспорт чараларының төрләре. | Балаларны транспорт төрләрен классификацияләү турында белемнәрен ныгыту. | январь |
| 18 | Хәрәкәтле уен: "ЮХИДИ инспекторы һәм транспорт йөртүче" | Балаларның өлкәннәр (ЮХИДИ инспекторы, машина йөртүче) хезмәте турындагы белемнәрен ныгыту. | |
| 19 | Казан шәһәрендәге метрополитен. | Метрополитен эше белән танышу, метро станцияләре, пассажирлар өчен кагыйдәләр турында сөйләү. Транспорт чараларын төрләргә классификацияләү буенча практик дәресләрне дәвам итү. Пассажирлар өчен кагыйдәләрне ныгыту | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20 | Хезмәт күрсәтүне белдерүче билгеләр. | Түбәндәге хезмәт күрсәтүне белдерүче билгеләрнең вазифаларын билгеләү буенча күнегүләр. "Автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү", "Автомобильләрне юу урыны", "Туклану пункты", "Хастаханә", "Автомобильләргә ягулык салу урыны", "Телефон", "Кунакханә яисә мотель", "Юл-патруль хезмәте посты". | февраль |
| 21 | Үстерешле уен "Артыгын алып куй" | Хезмәт күрсәтүне белдерүче билгеләр турындагы белемнәрне ныгыту. Фикерләүне үстерү. | |
| 22 | Тыючы билгеләр. | Балаларны "Транспорт белән керү тыела", "Борылу тыела", "Велосипедта хәрәкәт итү тыела", "Җәяүлегә хәрәкәт итү тыела", "Хәрәкәт тыела" тыючы билгеләре белән таныштыру; аларны башка билгеләрдән аерырга өйрәтү. | |
| 23 | Үстерешле уен: "Дөрес итеп күрсәт" | Тыючы билгеләртурындагы белемнәрне ныгыту. Игътибарны, фикерләүне үстерү. | |
| 24 | Боеручы билгеләр. | Боеручы билгеләр белән таныштыру: "Җәяүле юлы", "Велосипед юлы", "Әйләнүле хәрәкәт", "Хәрәкәт уңга", "Хәрәкәт сулга", "Хәрәкәт турыга". | март |
| 25 | Юл билгеләренең рәсемен ясау. | Балаларның юлдагы билгеләр турындагы белемнәрен ныгыту, аларны танырга өйрәтүне дәвам итү. | |
| 26 | Мәгълүмат бирүче һәм махсус урыннарны күрсәтүче билгеләр. | Мәгълүмат бирүче һәм махсус урыннарны күрсәтүче билгеләр белән аларның кайда урнашу-лары һәм вазифалары белән таныштыру. "Автобус яисә троллейбус туктау урыны", "Җәяүле-нең юлны аркылы чыгу урыны", , "Торак зона", "Торак зона чиге", "Туктау урыны", "Җәяүленең юлны җир асты аша чыгу урыны" һ.б. | |
| 27 | Үстерешле уен "Артык юл билгесе" | Балаларның юлдагы билгеләр турындагы белемнәрен ныгыту, аларны танырга өйрәтү.<br>Логик фикерләүне үстерү. | |
| 28 | Юл әлифбасы. | Балаларның җәяүлеләрнең урамда хәрәкәт итү, юлны аркылы чыгу кагыйдәләре турындагы белемнәрен ныгыту; юлның транспорт йөри торган өлеше, аеру полосасы (сызыгы) дигән төшенчәләр. "Ясалма тигезсезлек" билгесенең вазифасы турындагы белемнәрне ныгыту. | апрель |
| 29 | Юл билгесен куй. | Балаларны юл билгеләрен (кисәтүче, тыючы, боеручы, хезмәт күрсәтүне белдерүче билгеләр) аера белергә өйрәтү; пространствода ориентлашу күнекмәләрен ныгыту, | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | игътибарлылык тәрбияләү. | |
| 30 | Шәһәр урамы. | Балаларның юл йөрү кагыйдәләре, төрле транспорт төрләре турында белемнәрен ныгыту; шул темага кагылышлы сүзләрне актив кулланышка кертү. | |
| 31 | Юл билгеләре рәсемнәрен ясау. | Балаларның юл билгеләре турындагы белемнәрен тулыландыру, баету, ныгыту. | |
| 32 | Мин –үрнәк җәяүле. | Балаларның юлларда, җәмәгать транспортында үзләрен тоту кагыйдәләре, юл хәрәкәтен җайга салу, юл билгеләрен һәм махсус хезмәт номерларын файдалану турындагы белемнәрен ныгыту | май |
| 33 | Участоктагы юлда велосипедта йөрү. | Балаларның белемнәрен практикада куллану. | |
| 34 | Уен мәйданчыгында таби-гый материаллардан (ком, кирпеч һ.б.) урам төзү һәм анда балалар ясаган юл билгеләрен урнаштыру. | Балаларның алган белемнәрен ныгыту; киңлектә ориентлашу күнекмәләрен үстерү. Балаларның танып белергә кызыксынучанлыкларын, активлыкларын үстерү. | |
| 35 | "Могҗизалы юллар" викторинасын үткәрү. | Балаларның юл йөрү кагыйдәләре буенча белемнәрен арттыру һәм үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү. Балаларның игътибарлылыгын, мөстәкыйль эзләнүен, иҗади сәләтләрен үстерү. | |

**Перспектив план:**

**Иң гади математик күзаллаулар үстерү**

- Сентябрь

| Атналар | Тема: | Программа эчтәлеге: | Әдәбият: | Үтәү срогы | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|---|
| 1-атна | 1 дән 10 га кадәр саннар; математик бирем | 1 дән 10 га кадәр саннар турында белемнәрне ныгыту; математик биремнәрне чишәргә өйрәтү; математика шөгыленә кызыксыну тәрбияләү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| | Зур һәм кечкенә билгеләре белән танышу; таякчыклар белән эш | Санау таякчыклары ярдәмендә квадрат һәм турыпочмаклык төзәргә өйрәтү; зур һәм кечкенә билгеләрен тиешле урынга дөрес итеп урнаштыру; | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | . | |
| 2-атна | Зур, кечкенә, тигез билгесе, биеклек, кәгазь битендә ориентлашу | Зур, кечкенә, тигез билгесе турында белемнәрен ныгыту; предметның биеклеген чагыштырырга өйрәтү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | . | |
| | Кушу, алу билгесе белән танышу; математик биремнәрне чишү | Кушу һәм алу билгеләреннән дөрес итеп файдаланырга өйрәтү; математик биремнәрне чишәргә өйрәтү; математика шөгыленә кызыксыну тәрбияләү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |

- 
- Сентябрь
- 

| Атналар | Тема: | Программа эчтәлеге: | Әдәбият: | Үтәү срогы | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|---|
| 3-атна | Бирелгән сан буенча санарга өйрәтү; | Үрнәккә карап саный белергә өйрәтү; тигез, тигез түгел дигән төшенчәләрне аңлатуны дәвам итү; геометрик фигураларны кабатлау | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | . | |
| | Геометрик фигуралар; вакытта ориентлашу | Геометрик фигураларны танып белүне дәвам итү; тәүлек өлешләрен өйрәнүне дәвам итү; математика шөгыленә кызыксыну тәрбияләү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | . | |
| 4-атна | Зур, кечкенә билгеләре, предметларны сан белән тәңгәлләштерү | Саннар арасындагы зур, кечкенә билгеләрен дөрес итеп куярга өйрәтү; дәфтәр битенлә ориентлашуны ныгыту | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| | Логик биремнәр; геометрик фигуралар | Логик биремнәрне чишәргә өйрәтү; геометрик фигуралар турында белемнәрен арттыру; математика шөгыленә кызыксыну тәрбияләү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |

Октябрь

| Атналар | Тема: | Программа эчтәлеге: | Әдәбият: | Үтәү срогы | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|---|
| 1-атна | Предмет саны белән цифрны тәңгәлләштерү; математик бирем | Предмет саны белән цифрны тәңгәлләштерүне дәвам итү; математик биремнәрне чишүне ныгыту; математика шөгыленә кызыксыну тәрбияләү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Математик бирем; вакытта ориентлашу | Математик бирем не чишүне дәвам итү; сәгать белән таныштыру; зур кечкенә билгеләрен кабатлау | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| 2-атна | Предмет саны белән цифрны тәңгәлләштерүне дәвам итү; атна көннәре | Саннар арасында мөнәсәбәтләрне өйрәнүне дәвам итү; атна көннәре белән таныштыру; математика шөгыленә кызыксыну тәрбияләү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| | Логик бирем; вакытта ориентлашу | Атна көннәре турындагы белемнәрен ныгыту; логик биремне чишүне дәвам итү; математика шөгыленә кызыксыну тәрбияләү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | . | |
| 2-атна | Тәртип саны һәм бирелгән сан буенча санау; санны икегә бүлү | 10 эчендә тәртип саны белән санауны өйрәнүне дәвам итү; бирелгән сан буенча санарга өйрәтү;4 саннар арасындагы тигезсезлекне табаарга өйрәтү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | . | |
| | Арифметик мисаллар чишү; биеклекне өйрәнү | Саннар һәм тиешле билгеләрне дөрес итеп яза белергә ирешү; мәсьәләләрне чишә белергә өйрәтү;биеклекләрне линейка ярдәмендә үлчәргә өйрәтү; уйлау фикерләү сәләтен үстерү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | . | |
| 3-атна | Санны икегә бүлү; геометрик фигуралар | Геометрик фигуралар белән таныштыруны дәвам итү; саннар арасындагы тигезсезлекне табарга өйрәтү; дәфтәрдә оваллар рәсемнәргә тәгъдим итү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | . | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4 -атна | Вакытта ориетлашу, мисаллар чишү<br><br>Кабатлау | Кәгазь битендә ориетлашырга өйрәтүне дәвам итү; мисаллар чишү күнекмәләрен ныгыту; уйлау, фикерләү сәләтен үстерү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | . | |

Ноябрь

| Атналар | Тема: | Программа эчтәлеге: | Әдәбият: | Үтәү срогы | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|---|
| 1-атна | 11 саны белән таныштыру; | 1 дән 10 га кадәр саннарны кабатлау; логик фикерләү сәләтен үстерү; 11 санының ничек килеп чыгуын аңлату | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| 2-атна | Логик бирем; вакытта ориентлашу | Яңа санау берәмлеге дистә белән танышу; сәгатьбелән таныштыруны дәвам итү; математика шөгыленә кызыксыну тәрбияләү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| | Математик табышмаклар чишү; 11 санының 2 саннан барлыкка килүен аңлату | Геометрик фигураларны кабатлау; зур, кечкенә билгеләрен дөрес итеп куя белергә ирешү; нокталар ярдәмендә куян ясый алуга ирешү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| 3-атна | 12 саны вакытта ориентлашу | 12 саны белән таныштыру һәм дистә төшенчәсен аңлату; 12 санын язарга өйрәтү; математика шөгыленә кызыксыну тәрбияләү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| | Саннар арасындагы мөнәсәбәтләр; логик бирем, вакытта ориентлашу | Көзге айлар: Сентябрь, Октябрь, Ноябрь турында белемнәрен ныгыту; мисаллар чишүне дәвам итү; 11 һәм 12 саны арасындагы мөнәсәбәтне аңлату | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4-атна | Биеклек, логик бирем,геометрик фигуралар | Өчпочмакның элементлары белән таныштыру (ягы,почмагы, биек Һәм тәбәнәк ) төшенчәләрен ныгыту; мисаллар чишәргә өйрәтү +,- билгеләре ярдәмендә | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| | Биеклек, логик бирем,геометрик фигуралар (кабатлау) | Өчпочмакның элементлары белән таныштыру (ягы,почмагы, биек Һәм тәбәнәк ) төшенчәләрен ныгыту; мисаллар чишәргә өйрәтү +,- билгеләре ярдәмендә | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| 5-атна | 13 саны белән танышу; мисаллар чишү | Геометрик фигураларны кабатлау; 13 саны белән танышу һәм язарга өйрәтү; шакмакларга геометрик фигуралар ясый алуга ирешү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| | 13 санын кабатлау | Геометрик фигуралар турында белемнәрен ныгыту;түгәрәкне 2,3,4 өлешкә бүләргә өйрәтү;шакмактан эт ясый алуга ирешү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |

Декабрь

| Атналар | Тема: | Программа эчтәлеге: | Әдәбият: | Үтәү срогы | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|---|
| 1-атна | Мисаллар чишү; кушу, алу билгеләрен ныгыту | Мисалларны чишә һәм дөрес итеп укый белергә өйрәтү; кушу, алу билгеләре турында белемнәрен ныгыту; биек, тәбәнәк төшенчәләрен өйрәтү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Логик биремнәр, геометрик фигуралар | Кушу, алу билгеләрен дөрес итеп куя белергә өйрәтү; биек, тәбәнәк төшенчәләрен ныгыту; логик фикерләү сәләтен үстерү; өчпочмак турында белемнәрен ныгыту | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| 2-атна | 14 саны белән танышу; атна көннәре | 14 санының килеп чыгуын аңлату; 14 санын язарга өйрәтү; логик мисалларны чишә алуга ирешү; кузаллау һәм фикерләү сәләтен үстерү; атна көннәре турында белемнәрен ныгыту | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |
| | Атна көннәрен кабатлау; 14 саны белән танышуны дәвам итү | Кузаллау һәм фикерләү сәләтен үстерү; атна көннәре турында белемнәрен ныгыту; 14 саны белән танышуны дәвам итү; математика шөгыленә кызыксыну тәрбияләү | Е.В.Колесникова “Математика для детей 6-7 лет” | | |

Декабрь- Январь

| Атналар | Тема: | Программа эчтәлеге: | Әдәбият: | Үтәү срогы | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|---|
